


Рузаевка шәһәренен беренче гимназиясендәге 11 нче сыйныф укучылары Елена Осыка һәм Алина Бикбаева «Большая перемена» Ботенроссия конкурсында икенче ел катнашалар.
Узган елда Алина Бикбаева «Зур тәнәфес» конкурсынын ярымфиналына vткән иде. Ул Тvбән Новгородта узды. Бу юлы дәрәжәле конкурснын ярымфиналына 11 нче сыйныф укучысы Елена Осыка vтте. Ул Казанда булып, онытылмаслык хис-кичерешләр белән кайткан. - «Зур тәнәфес» - доньяны vз-гәртергә һәм vзен vзгәрергә әзер булган кешеләр берләшмәсе. Биредә бәяләv тvгел, ә стандарт булмаган фикерләv сәләте житәкчелек итә. Бу конкурс сәләтлеләр очен урын. Әлеге кызыклы бәйгедә катнашучылар белемнәрен мәктәп программасы буенча гына тvгел, ә аны кинәйтергә, ижат итәргә, стандарт булмаган фикерләvне кvрсәтергә момкинлек бирә; vзенә vзгәрергә һәм доньяны vзгәртергә әзер булганнар жәмәгатьчелеге, - ди Алина, конкурс эчтәлеге турында сорагач.
Чыгарылыш сыйныф укучысы сvзләренә караганда, vткән ел ярымфиналга эләгv шактый авыр булган. Монын очен кvп эшләргә һәм кvп нәрсә белергә кирәк, ди. Үткән ел Алина Бикбаева сәламәт яшәv рәвеше юнәлешен сайлаган. Жюри хокеменә ул сәламәт туклану һәм диетология буенча проект тәкъдим иткән. Быел Ботенроссия конкурсында vз кочен сынап караган Алина Бикбаева:
- 2021 елда мин «Зур тәнәфес» финалынын чирегенә уздым, әмма мина ярымфиналга эләгv очен берничә балл житмәде. Быел «Эшмәкәр» дип аталган юнәлешне сайладым. Мин килеп туган эпидемия шартларында мәгарифкә ачкычлар таптым. Укучыларнын барлык мәнфәгатьләрен исәпкә алырдай уку-укыту программасын эшләргә кирәк иде.
Кызыксынулары Алина Бикбаева-нын торле юнәлештә булуга карамастан, ул табиб булырга хыяллана. Шуна кvрә медицина институтына укырга керергә планлаштыра. Алинага хыялынын тормышка ашуын телисе килә.